ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.15 статья өстәргә:

“2.15. статья. **Террорчылыкны профилактикалау, аның чагылышларыннан килгән зыяннарны минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча коллегиаль орган карарларын үтәмәү яисә бозу**

1. Татарстан Республикасында федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының террорчылыкны профилактикалау, шулай ук аның чагылышларыннан килгән зыяннарны

минимальләштерү һәм (яисә) бетерү эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Президенты карары белән төзелгән коллегиаль орган (әлеге статьяда алга таба – Татарстан Республикасының террорчылыкны профилактикалау органы) компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарны үтәмәгән яисә бозган өчен, –

гражданнарга – өч мең сум; вазыйфаи затларга – егерме мең сум; юридик затларга илле мең сум күләмендә административ штраф салына.

2. Татарстан Республикасының бер яисә берничә муниципаль берәмлеге территорияләрендә террорчылыкны профилактикалау, аның чагылышларыннан килгән зыяннарны минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча Татарстан Республикасының террорчылыкны профилактикалау органы җитәкчесе карары белән төзелгән коллегиаль орган компетенциясе чикләрендә кабул ителгән карарны үтәмәгән яисә бозган өчен, –

гражданнарга – бер мең сумнан алып өч мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш мең сумнан алып ун мең сумга кадәр; юридик затларга – утыз мең сумнан алып илле мең сумга кадәрге күләмдә административ штраф салына.";

2) 7.1 статьяда "2.11 – 2.14" саннарын "2.11 – 2.15" саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 7[1] өлеш өстәргә:

"7[1]. Әлеге Кодексның 2.15 статьясындагы 1 өлешендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләрне Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының вазыйфаи затлары төзи.";

б) 14 өлештә "2.12 – 2.14" саннарыннан соң ", 2.15 статьяның 2 өлешендә" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

"Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында" 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш), "2.12 – 2.14," саннарыннан соң "2.15 статьяның 2 өлешендә," сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 07 ноябрь
№ 87-ТРЗ